# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**22.11.2024ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1.«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, күпбалалы гаиләләрдән тыш

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1)Дружба торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш салу, зиратка юлны грейдерлау, эшләр өчен шартнамә буенча түләү);

2) Дружба торак пунктында су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен тирәнлек насосны сатып алу).

3.Әлеге карарны Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru).

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлеге башлыгы ________ А.М.Галимов